**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: : 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 нчы елның 26 нчы апреле 169№

**2019 нчы елда урманнарны янгыннардан саклау буенча янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары һәм Әлки муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында**

2019 нчы елда язгы-җәйге янгын куркынычы чоры башланып район торак пунктларында янгын куркынычы арту сәбәпле, Әлки муниципаль районы торак пунктларында янгын куркынычын булдырмау, объектларны һәм торак пунктларны үз вакытында әзерләү максатыннан, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 нчы елның 15 нче апрелендәге 294 номерлы “Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында" Карарын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Урман кодексының 52-53[8], 83, 96 һәм 97 статьялары, 1994 нче елның 21 нче декабрендәге 68-ФЗ номерлы "Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" 69 —ФЗ№ "Янгын куркынычсызлыгы турында» федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 нче елның 30 нчы июнендәге 417 номерлы “Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында" карары нигезендә, һәм урманнарны янгыннардан саклау системасының нәтиҗәлелеген арттыру, учреждениеләрне 2019 нчы елгы янгын куркынычы сезонына үз вакытында һәм сыйфатлы әзерләүне тәэмин итү һәм Әлки муниципаль районында янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәүне контрольдә тоту максатларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.2019 нчы елның 15 нче апреленнән Әлки муниципаль районы территориясендә янгын куркынычы сезоны башлануны билгеләргә.

2. 2019 нчы елда Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә урманнарны янгыннардан саклау эшен оештыру буенча чаралар планын расларга. Кушымта 1№

3.Төрле милек формасындагы оешма җитәкчеләренә урман янгыннарын сүндерү планы нигезендә урман янгыннарын сүндерү өчен көч һәм чаралар бүлеп бирүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе Йосыпов И.В

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Башкарма комитетының
20___ нчы елның ____________ ____ № Карарына
1 нче Кушымта

# Әлки муниципаль районы территориясе урманнарын 2019 елда янгыннардан саклау эшен оештыру буенча чаралар планы

| т/б № | Чаралар исемлеге | Башкаручы | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|
| | **Оештыру чаралары** | | |
| 1 | Янгын-куркыныч чоры буенча чаралар комплексын үтәү | “Әлки урманчылыгы " ДКУ | 2019 нчы елның 25 нче апреленә кадәр |
| 2 | Гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия утырышын уздыру (янгын сезонына әзерлек буенча төп чаралар планын эшләү һәм раслау) | Районның ГТХ һәм ЯКТК, ӘМР “ГЯИ” МКУ, ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ “ТРбуенча ФЯКХ 7 отряд” ФДКУ, КПБ | апрель |
| 3 | Урман фонды җирләренең маршрутларын эшләү һәм патрульләү графикларын раслау | “Әлки урманчылыгы " ДКУ“,ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ “ТРбуенча ФЯКХ 7 отряд” ФДКУ | 2019 нчы елның 25 нче апреленә кадәр |
| 4 | Урман янгыннарын сүндерүгә әзерлек максатларында, ӘМР ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ “ТРбуенча ФЯКХ 7 отряд” ФДКУ белән үзара хезмәттәшлек итү буенча практик дәресләр һәм күнекмәләр үткәрү. “Әлки урманчылыгы” ДКУ җитәкчеләрен, хезмәткәрләрен, урман янгыннарын сүндерү белгечләрен өйрәтү.<br>«Әлки урманчылыгы» ДКУ, ӘМР ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ “ТРбуенча ФЯКХ 7 отряд” ФДКУ һәм РСЧС ТП ведомство буйсынуындагы учреждениеләр көчләренең һәм чараларының үзара бәйләнешен эшләү буенча өйрәнүләр үткәрү | Районның ГТХ һәм ЯКТК, ӘМР “ГЯИ” МКУ, ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ “ТРбуенча ФЯКХ 7 отряд” ФДКУ, “Әлки урманчылыгы " ДКУ | апрель |
| 5 | Урман янгыннарын космик мониторинглау мәгълүматын кабул итүне һәм анализлауны тәэмин итү | “Әлки урманчылыгы " ДКУ, ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ “ТРбуенча ФЯКХ 7 отряд” ФДКУ | Янгын куркынычы сезоны дәвамында |
| 6 | Югары янгын куркынычы туганда халыкның урманнарга керүен чикләү буенча башкарма комитет күрсәтмәләрен (карарын ) үз вакытында әзерләүне тәэмин итү | Районның ГТХ һәм ЯКТК, ӘМР “ГЯИ” МКУ, ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ “ТРбуенча ФЯКХ 7 отряд” ФДКУ, КПБ, районның АҖ башлыклары. | Янгын куркынычы сезоны дәвамында |
| 7 | Урман массивларына һәм торфяникларга тоташкан торак пунктлар | Районның ГТХ һәм ЯКТК, ӘМР | апрель - май |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | һәм объектлар чикләрендә янгынга каршы киртәләр һәм минераллаштырылган полосалар системаларының торышын тикшерү | “ГЯИ” МКУ, ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ “ТРбуенча ФЯКХ 7 отряд” ФДКУ, КПБ, районның АҖ башлыклары, АҖ җитәкчеләре. | |
| 8 | Урман массивларын һәм торфяникларны патрульлек итү һәм күзәтүне беркетергә. Барлыкка килгән янгыннарны бетерүгә көч һәм чараларны, шулай ук торак пунктларның кеше ресурсларын җәлеп итәргә. | ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ “ТРбуенча ФЯКХ 7 отряд” ФДКУ, КПБ, районның АҖ башлыклары, “Әлки урманчылыгы " ДКУ | июнь - сентябрь |
| 9 | Янгынга каршы кисәтү, профилактик чаралар комплексын үткәрүне тәэмин итү һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне контрольдә тоту. | ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ “ТРбуенча ФЯКХ 7 отряд” ФДКУ, КПБ, “Әлки урманчылыгы " ДКУ | Янгын куркынычы сезоны дәвамында |
| 10 | Иң күп йөри торган урыннарда (беренче чиратта, торак пунктлардан чыгу юлында автомобиль юллары буйларында янгыннарны кисәтү, урманнарга һәм торфяникларга керүне тыю турында билгеләр) янгынга каршы тематикалы билбордлар һәм баннерлар сериясен урнаштыруны тәэмин итү | ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ “ТРбуенча ФЯКХ 7 отряд” ФДКУ, КПБ, районның АҖ башлыклары, “Әлки урманчылыгы " ДКУ | июнь - сентябрь |
| 11 | Үткәрелә торган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны һәм урманнарның һәм торак пунктларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә проблемалы мәсьәләләрне, янгыннарның оператив хәлен яктыртуны оештыру, шулай ук халыкка көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чаралары турында хәбәр итү | “Әлки хәбәрләре” газетасы, ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ “ТРбуенча ФЯКХ 7 отряд” ФДКУ, КПБ, районның АҖ башлыклары, “Әлки урманчылыгы " ДКУ | июнь - сентябрь |
| 12 | Авыл җирлекләре башлыклары һәм объектлар җитәкчеләре белән берлектә объектлар һәм торак пунктлар территорияләрен чүп-чардан һәм коры-сарыдан чистартуга ирешергә | районның АҖ башлыклары,оешма җитәкчеләре | июнь - сентябрь |
| 13 | Ирекле янгын формированиеләренең әзерлеген тикшерү һәм ярдәм итү | ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ “ТРбуенча ФЯКХ 7 отряд” ФДКУ, КПБ, районның АҖ башлыклары, “Әлки урманчылыгы " ДКУ | июнь - сентябрь |
| 14 | Янгын куркынычы булган сезонга резерв — ягулык - майлау материаллары булдыруны тәэмин итү | “Әлки урманчылыгы " ДКУ | ел буена |
| 15 | Урман фонды җирләрендә, урман массивлары янында урнашкан торак пунктларда территорияләрне төзекләндерүне тәэмин итү | “Әлки урманчылыгы " ДКУ,Башкарма Комитет ( килешү буенча) | апрель - октябрь |